«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары төзү турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 18 гыйнварындагы 22 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 1 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, «Сәяси партияләр турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 2 октябрендәге 157-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 7 өлеше нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары төзү турында» 2013 елның 18 гыйнварындагы 22 номерлы карарына кушымтага кертергә (24.03.2014 ел, № 199, 25.08.2014 ел, № 521, 09.02.2015 ел, № 58, от 03.09.2015 ел № 362, 29.01.2016 ел, № 47, 29.07.2016 ел, № 469, 30.09.2016 ел, № 565, 11.11.2016 ел, № 687) һәм түбәндәге үзгәрешләрне расларга:

1) 14 нче пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

**«14. <u>1346нчы Татар Шатрашаны сайлау участогы</u>**

Үзәк – Татар Шатрашаны авылында күпфункцияле үзәк Чүпрәле муниципаль районы, Татар Шатрашаны авылы, Чкалов ур., 20 йорт, тел. 33-4-10.

Сайлау участогы чикләренә Татар Шатрашаны авылы керә.

Сайлаучылар саны-238.»;

2) 35 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35. **<u>Иске Әлмәле сайлау участогы № 1367</u>**

Үзәк – Чүпрәле муниципаль районы мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге балалар өчен «Иске Әлмәле башлангыч мәктәбе – балалар бакчасы», Иске Әлмәле авылы, Үзәк урамы, 23, тел.32-6-02.

Сайлау участогы чикләренә Иске Әлмәле авылы керә.

Сайлаучылар саны-320.».

2. Әлеге карарны Чүпрәле районының «Туган як» газетасында бастырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкче Вазыйфаларын башкаручы А. С. Полюшков